ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 448-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Прокуроры тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 448-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2025 елның 18 апреле
№ 268-VII ДС

проект
Татарстан Республикасы
прокуроры тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»**

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2013, № 1, № 5; 2014, № 4, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 4, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 90 (I өлеш), № 96 (I өлеш); 2023, № 92 (I өлеш), № 95 (I өлеш); 2024, № 16 (I өлеш), № 28 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) беренче абзацта «Реабилитацияләнгән гражданнарга» сүзләрен «1. Реабилитацияләнгән гражданнарга» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 2 пункт өстәргә:

«2. Репрессияләр аркасында торак урыннарын югалткан реабилитацияләнгән гражданнар, алар Татарстан Республикасы территориясендәге элеккеге яшәү урынына (репрессияләргә дучар ителгәнгә кадәр яшәгән җирләргә һәм торак пунктларга) кайткан очракта, һәм аларның гаилә әгъзалары торак урыннарга мохтаҗ дип таныла. Әлеге затлар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә исәпкә алына һәм торак урыннар белән тәэмин ителә. Бу хокук шулай ук репрессияләнгән затлар белән алар репрессияләргә дучар ителгәнгә кадәр бергә яшәгән аларның гаилә әгъзаларына һәм башка туганнарына, шулай ук иректән мәхрүм итү урыннарында, сөргендә, махсус яшәү урынында туган балаларга да кагыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

# АҢЛАТМА

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты «Сәяси репрессияләр корбаннарын реабилитацияләү турында» 1991 елның 18 октябрендәге 1761-1 номерлы Россия Федерациясе Законының (алга таба – Реабилитация турындагы закон) 13 статьясы нигезләмәләрен гамәлгә ашыру максатларында эшләнгән.

Реабилитация турындагы законның күрсәтелгән нормасы нигезендә репрессияләр аркасында торак урыннарын югалткан реабилитацияләнгән затларның репрессияләргә дучар ителгәнгә кадәр яшәгән җирләргә һәм торак пунктларга кайту хокукы танылa. Реабилитацияләнгән затлар һәм аларның гаилә әгъзалары элеккеге яшәү урынына кайткан очракта Россия Федерациясе субъектлары законнарында каралган тәртиптә исәпкә алына һәм торак урыннар белән тәэмин ителә. Бу хокук шулай ук репрессияләнгән затлар белән алар репрессияләргә дучар ителгәнгә кадәр бергә яшәгән аларның гаилә әгъзаларына һәм башка туганнарына, шулай ук иректән мәхрүм итү урыннарында, сөргендә, махсус яшәү урынында туган балаларга да кагыла. Туганнарның репрессияләренә бәйле мәҗбүри күченү факты документлар белән расланмаганда, әлеге фактны суд билгели ала.

2019 елның 10 декабрендәге 39-П номерлы Россия Федерациясе Конституция суды карары нигезендә реабилитацияләнгән затларның элеккеге яшәү урыннарына кайткан очракта торак урыннар белән тәэмин ителү хокукы һичшиксез үтәлергә тиеш һәм башка категория гражданнары өчен торак законнары белән билгеләнгән шартларны үтәмичә гамәлгә ашырыла һәм Реабилитация турындагы законның 13 статьясы нигезләмәләрен исәпкә алып, аны үтәү дәүләт хакимияте органнарының бурычы булып тора.

Татарстан Республикасында репрессияләр аркасында торак урыннарын югалткан реабилитацияләнгән затларны, алар репрессияләргә дучар ителгәнгә кадәр яшәгән җирләргә һәм торак пунктларга кайткан очракта, исәпкә алу һәм торак урыннар белән тәэмин итү тәртибен билгеләү бу бурычны үтәүгә, әлеге категория затларының алар репрессияләргә дучар ителгәнгә кадәр үзләре һәм (яисә) ата-аналары яшәгән җирләргә кайтуның дәүләт (федераль закон чыгаручы) тарафыннан танылган хокукын гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән.

Реабилитацияләү турындагы законның 13 статьясында билгеләнгән хокукны гамәлгә ашыру Россия Федерациясенең күп кенә субъектлары законнарында, мәсәлән, Чуваш Республикасының «Торак мөнәсәбәтләрен җайга салу турында» 2005 елның 17 октябрендәге 42 номерлы Чуваш Республикасы законында (хокук аңа 2021 елның 24 декабрендәге 104 номерлы Чуваш Республикасы законы белән кертелгән үзгәреш нигезендә билгеләнгән); «Түбән Новгород өлкәсендә торак сәясәте турында» 2007 елның 7 сентябрендәге 123-З номерлы Түбән Новгород

өлкәсе Законында; «Башкортстан Республикасында сәяси репрессияләр корбаннарына социаль ярдәм турында» 2004 елның 17 декабрендәге 133-з номерлы Башкортстан Республикасы Законында; «Марий Эл Республикасында аерым категория гражданнарына социаль ярдәм һәм аларга социаль хезмәт күрсәтү турында» 2004 елның 2 декабрендәге 50-З номерлы Марий Эл Республикасы Законында; «Мордовия Республикасында яшәүче халыкның аерым категорияләренә социаль ярдәм чаралары турында» 2004 елның 28 декабрендәге 102-З номерлы Мордовия Республикасы Законында; «Оренбург өлкәсе территориясендә аерым категория гражданнарына торак урыннар бирү турында» 2007 елның 13 июлендәге 1347/285-IV-ОЗ номерлы Оренбург өлкәсе Законында; «Самара өлкәсе территориясендә яшәүче аерым категория гражданнарын торак урыннар белән тәэмин итү турында» 2006 елның 11 июлендәге 87-ГД номерлы Самара өлкәсе Законында; «Саратов өлкәсендә торак урыннар бирү турында» 2005 елның 28 апрелендәге 39-ЗСО номерлы Саратов өлкәсе Законында һәм башкаларда билгеләнгән.

Россия Федерациясе Торак кодексының 49 статьясындагы 3 өлеше нигезендә Россия Федерациясе субъекты торак фондының торак урыннары социаль наем шартнамәләре буенча Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән нигезләр буенча торак урыннарга мохтаҗ дип танылган гражданнар категорияләренә бирелә ала. Бу торак урыннар, әгәр Россия Федерациясе субъекты законында башка тәртип каралмаган булса, Россия Федерациясе Торак кодексында билгеләнгән тәртиптә бирелә.

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, карала торган Татарстан Республикасы законы проекты белән репрессияләр аркасында торак урыннарын югалткан реабилитацияләнгән гражданнар, алар Татарстан Республикасы территориясендәге элеккеге яшәү урынына (репрессияләргә дучар ителгәнгә кадәр яшәгән җирләргә һәм торак пунктларга) кайткан очракта, һәм аларның гаилә әгъзалары торак урыннарга мохтаҗ дип танылa.

Әлеге затларны исәпкә алу һәм торак урыннар белән тәэмин итү тәртибен билгеләү вәкаләтен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирү тәкъдим ителә.

Репрессияләр аркасында торак урыннарын югалткан реабилитацияләнгән затларны, алар Татарстан Республикасындагы элеккеге яшәү урынына кайткан очракта, һәм аларның гаилә әгъзаларын исәпкә алу һәм торак урыннар белән тәэмин итү тәртибен раслау турында карар проекты Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан эшләнде.

Проект нигезендә репрессияләр аркасында торак урыннарын югалткан реабилитацияләнгән гражданнарны, алар Татарстан Республикасындагы элеккеге яшәү урынына кайткан очракта, һәм аларның гаилә әгъзаларын торак урыннар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Шул ук вакытта җирле үзидарә органнарына реабилитацияләнгән гражданнарны исәпкә алу һәм социаль наем шартнамәсе буенча торак урыннар белән тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен беркетү өчен җирле үзидарә

органнарына тиешле вәкаләтләр бирү турындагы Татарстан Республикасы законын кабул итү таләп ителәчәк.

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законын кабул итүгә бәйле рәвештә җирле үзидарә органнарына реабилитацияләнгән гражданнарны исәпкә алу һәм социаль наем шартнамәсе буенча торак урыннар белән тәэмин итү вәкаләтләрен бирү турындагы Татарстан Республикасы законын, шулай ук Репрессияләр аркасында торак урыннарын югалткан реабилитацияләнгән гражданнарны, алар Татарстан Республикасындагы элеккеге яшәү урынына кайткан очракта, һәм аларның гаилә әгъзаларын исәпкә алу һәм торак урыннар белән тәэмин итү тәртибен раслау турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын кабул итү таләп ителәчәк.

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

Карала торган «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектында репрессияләр аркасында торак урыннарын югалткан реабилитацияләнгән гражданнарны, алар Татарстан Республикасындагы элеккеге яшәү урынына кайткан очракта, һәм аларның гаилә әгъзаларын торак урыннар белән тәэмин итү аларга социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү юлы белән гамәлгә ашырылачагы күздә тотыла.

Шул ук вакытта җирле үзидарә органнарына реабилитацияләнгән гражданнарны исәпкә алу һәм социаль наем шартнамәсе буенча торак урыннар белән тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен беркетү өчен җирле үзидарә органнарына тиешле вәкаләтләр бирү турындагы Татарстан Республикасы законын кабул итү таләп ителәчәк.

Әлеге вәкаләтләрне гамәлгә ашыру, тиешле чыгым йөкләмәләрен кабул иткән очракта, Татарстан Республикасы бюджетыннан хәзерге вакытта күләмен бәяләү мөмкин булмаган өстәмә чыгымнарга китерәчәк.